ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“ 11 ” ноябрь 2024 ел　　　　Борды авылы　　　　№ 18

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең Жэйлэу авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Борды авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл жирлеге Советынын 07.11.2019 елнын 51/1 номерлы карары белэн “Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл жирлеге составына керуче торак пунктларда гражданнар жыенын эзерлэу һәм уткэру тэртибе турында “Нигезлэмэне раслау хакында”

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең Жэйлэу авылында 2024 елның 22 ноябрендэ 09.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Борды авыл җирлегенең Жэйлэу авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Борды авыл җирлегенең Жэйлэу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Борды авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (Жэйлэу авылында launched зиратта хужалык блогы ремонтлау)

“ӘЙЕ”　　　　　　　　“ЮК”.

3.Татарстан Республикасы, Тукай районы, Жэйлэу авылы, Кыр урамы, 1 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

4.Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6.Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Борды авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Абдульманова